**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 декабрь № 993

г. Казань

Ф.Ә.Табиев истәлеген мәңгеләштерү турында

Атаклы Совет партиясе һәм дәүләт эшлеклесе, КПССның Татарстан обкомы беренче секретаре (1960 – 1979 еллар) Фикрәт Әхмәтҗан улы Табиев истәлеген мәңгеләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең, Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең, Түбән Кама муниципаль районының атаклы Совет партиясе һәм дәүләт эшлеклесе, КПССның Татарстан обкомы беренче секретаре Фикрәт Әхмәтҗан улы Табиев истәлеген мәңгеләштерү турындагы инициативаларын хупларга.

2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына Ф.Ә.Табиевка мемориаль такта эшләргә һәм Казан шәһәре, Большая Красная ур., 65 нче йорт адресы буенча урнашкан бина фасадына куярга, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Ф.Ә.Табиев тормышы һәм эшчәнлеге турында «Фикрят Табеев. Философия оптимизма» китабын яңадан бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә, Ф.Ә.Табиевка мемориаль такта эшләү һәм Ф.Ә.Табиев тормышы һәм эшчәнлеге турында «Фикрят Табеев. Философия оптимизма» китабын яңадан бастырып чыгару өчен кирәкле чыгымнар суммасын билгеләргә.

5. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына Ф.Ә.Табиев исемен түбәндәгеләргә бирү турындагы мәсьәләләрне карарга тәкъдим итәргә:

Казан шәһәре Декабристлар урамында «Идел-Пресс» матбугат-нәшрият комплексы бинасы янында урнашкан скверга;

Казан шәһәрендәге «Весна» торак комплексында яңадан төзелә торган урамга.

6. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Казан (Идел буе) федераль университеты белән берлектә, 30 көн эчендә Татарстан Республикасының югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентлары һәм аспирантлары өчен Ф.Ә.Табиев исемендәге стипендияләрне гамәлгә кую буенча тәкъдим кертергә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\993.doc